**Тема:  Начар гәдәтләр. Аракы эчү һәм гаилә. (1 нче дәрес)**

**Максат:**

1. Исерткеч эчемлекләр куллануның зыянын курсәтү.
2. Эчүчәлекнең иҗтимагый бәла, кеше тормышындагы житешсезлекләрнең төп чыганагы.
3. Исерткеч эчемлекләр куллануның сәламәтлекне какшатучы  дошман икәнлегенә төшендерү.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Исерткеч эчемлекләргә карата нәфрәт уяну.
- Киләчәк тормыш өчен үзеңне җаваплы итеп тою.
- Үз-үзеңне кулда тота белергә өйрәнү.

**Эпиграф:** *"Дөньяда хур буласың килсә, аракы эч".*

/Татар халык мәкаләсе/

**Дәрес барышы**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*"Улларым өшегән, ирем асылынган."*

*Поезд вагонына тукталыштан сон бер егет килеп керә. Керә дә ашык-пошык өстәлгә ризыклар, бер шешә аракы һәм кружка алып куя. Аның тизрәк шешәне ачасы килүе күренеп тора. Моңа кадәр дәшмичә генә утырган хатын телгә килә.*

*- Эчмә, егет.*

*- Суыкта торып өшетте, җылыныр өчен генә.*

*- Өшедем дисеңме? Өшүнең нәрсә икәнен беләсеңме соң син!?-дип хатын уз язмышын сөйләргә кереште:*

*- Өченче баламны алып кайтырга йөрим. Больница шактый ерак, тулгак башлангач кына әллә барып җитеп була, әллә юк. Ирем Закир белән киңәшләштек тә, бер-ике көн алдан барып куну ышанычлырак булыр, дип уйладык Шулай иттек тә.*

*Мин әйберләрне җыйганда ике улым гел аяк астында буталдылар.*

*- Кызлар кирәкми безгә әни, карап ал, елак булмасын. Елак булса өйгә дә кертмибез!- диделәр.*

*Кереп урнашкач, больница ишеге төбендә утырган ирем белән саубуллашырга чыктым."Эчеп йөрмә инде син", - дим.*

*- Менә исән-сау котылып кайткач, туганнар белән бергәләп утырырбыз."*

*Кызу кеше ул -кукерт сыман шунда ук кабынып китте:"Нинди бетмәгән суз булды- эчмә дә эчмә! Иртәгә эшкә бит! Юкны уйлап ятма. Гөл иттереп торырбыз малайлар белән."*

*Аракының колына әйләнеп беткәч- эчмиме сон! Башта шофер белән ашханәгә төшеп бер шешә бушатканнар. Шуннан сон туры өйгә кайткан әле ул. Курше әби әйтә, бик озак йортында булышты, ди.Малларны караган , балаларнын тамагын туйдырган. Берара малайларны .чанага утыртып, шау-гөр килеп чабып йөрде, ди. Шунда тукталып калса иде дә! Эңгер-меңгер төшкәч, тагын авыл арасына чыгып киткән. Абыйларга кереп кунак булган. Гел:"Минем малайлар, минем малайпарым..."-дип, мактанып утырды",-ди җиңгәсе. Тагын кайдадыр аракыны өстәгәч, төн уртасында гына сөйрәлеп өйгә кайткан.*

*Ә малайлар, тыючы булмагач, уйнап сугышып рәхәтләнгәннәр, өйне астын-өскә китергәннәр. Берсе, ялгыштыр инде, телевизорга бәрелгән. Пыяла, чылтырап кына коелган...*

*Мин ул көнне йоклый алмадым. Әллә яңа урынны килештермәдем. Күңел борчылды. Түзә алмагач, рөхсәт сорап, урамга чыктым. Нык суытып җибәргән,салкын җил исә. Озак кына авыл ягына карап тордым. Өшеп, туңып беткәч кенә урыныма кереп яттым. Шул чак тәрәзәгә ике кош килеп бәрелде. Әйтерсен, бүлмәгә җылынырга керергә сорыйлар. Мин*

*йоклый алмый боргаланам, алар тәрәзәгә сарылалар... Иртүк куркып уянып киттем. Бераздан бәбәйли башладым.*

*Ә Закир, ватык телвизорны күргәч, тәртипкә өйрәтә янәсе, малайларны ялан өс килеш тышка куып чагара да, ишекне бикләп куя. Бераз торырмын да, кертермен дигәндер дә соң...*

*Эчкәч йоклый торган гадәте бар анын. Күпме вакыт үткәндер, кем белә... Малайларны искә төшереп чыккандырмы, башка нәрсәгәме? Ул ишекне килеп ачкач, өйалдыннан җиргә бер-берсеннән аерып ала алмаслык булып ябышып туңган ике балам егылып төшә...*

*- Закирнын салкын гәүдәсен элмәктән күршеләр иртән генә кисеп төшерәләр...*

*- Ичмасам, яңа туганы да гомерле булмады. Аны тапканның икенче көнендә үк больницадан чыгып салкын кабер авызына иремне, ике баламны озатып куйдым. Төшме, өнме икәнен аерырлык хәлдә түгел идем. Сөтем бетте, яшь балам барлыгын да онытым бугай. Ашадыммы, эчтемме, йокладыммы- белмим. Зиратка барам, өйгә кайтам, аннан тагын зиратка китәм.*

*Уйланып-уйланып утырам да, ишек төбенә болдырга чыгып басам. Тешләр тешкә тиеп калтыраганчы суыкта яланаяк басып торам. Улларым да шулай өшегәннәрдер, дим. Алар соңгы тапкыр башларын терәгән урынга кагылам. Жиңнелрәк булып китә. Аннан абзарга чыгып, бау чалынган киртә астына басам.”Йә, күңелең тынычландымы?-дим- Балаларны да кабергә керттең, үзең дә шулар артыннан киттең. Инде эчәсең килмидер. Мине генә кемгә калдырдың?”*

*- Эчмә син, егет. Эчмә...*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Аракы эчү һәм гаилә).

**III.Уку мәсьәләсен чишү.**

**1. Төркемнәрдә эшләү.**

**1нче бирем “*Ике исем*”**

- Текстка ике исем кушыгыз:
    - беренчесендә аның темасы күренсен. (*Бер гаиләнең язмышы).*
    - икенчесендә- текстның төп фикере ачыклансын. (*Аракы фаҗигага китерә).*

**2нче бирем *Үгет- нәсыйхәт.***

- Закир абый шикелле аракыны яратучыларга нинди үгет- нәсыйхәт, киңәш бирер идегез?
- Бу фаҗигане булдырмый калырга мөмкин идеме?
- Мөмкин иде әгәр:
    - Закир абый аракы гел эчмәсә;
    - аз гына эчкәч тә туктап кала алса;
    - хатыны өйдә юкта җаваплылык тойса.
- Димәк, аракы- бәхетсезлекнең, хәсрәтнең, фаҗиганың башы.

**3нче бирем *Атасы- анасы еш кына исерек булган баланың хис- тойгылары.***

- Атасы- анасы еш кына исерек булган баланың хис- тойгыларын күз алдына китерегез. Ул нәрсә турында уйлый? (Ул борчыла, кайгыра, курка, чирли; иптәшләре ашаганны ашый алмый, кигәнне кими, чөнки бөтен акчаны аракы “ашый”).
- Тормышта карап тырышка акыллы кешеләр дә еш кына аракы эчәләр. Ни өчен? (Туйлар, бәйрәмнәр уздырганда, эштә үзара килешүләр төзегәндә).
- Эчүнең чамасын белергә кирәк диләр. Чамасын белеп кенә эчеп буламы?

(Башта чамасын белсә дә, соныннан чаманы белеп булмый).

**4нче бирем *Закир абый улларының соңгы сүзләре, уйлары.***

- Үзегезне кыш көнне урамга куып чыгарылган ике малайның урынында үзегезне күз алдыгызга китерегез. Закир абый улларының нинди булган микән соңгы сүзләре, уйлары? Алар исеменнән, алар булып әйтеп карагыз. (Әтием- җаным, керт йөгә- без туңдык. Әти, гафу ит, без бүтән әйбер ватмабыз! Уян, әти, без инде түзә алмыйбыз!)
- Бу хикәя сездз нинди уй- фикердәр барлыкка китерде? Эчүчелек-афәт, эчүчелек-үлем ул!)

**5нче бирем** ***Текста күтәрелгән проблемаларны***

- Алкоголизм һәм гаилә проблемасы.
- Гаиләдәге мөнәсәбәтләр проблемасы.
- Ата- аналар һәм балалар проблемасы.
- Ата кешенең җавапсызлык проблемасы.
- Исереклек һәм фаҗига, үлем проблемасы.
- Бәхетсез гаиләләр проблемасы.
- Үз- үзеңә кул салу проблемасы.

**2. Уен "Мин башлыйм, син дәвам ит"** (Мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итәләр).

- Балалар! Хәзер уен уйнап алыйк! Мәкальләрне мин башлыйм- сез дәвам итәрсез.

Аракы — сатып алынган ... *чир ул.*
Аракы сүзне озайта, гомерне ... *кыскарта.*
Исерек акчасын гына эчми, ... *акылын да эчә.*
Аракы — гөнаһның ... *анасы.*
Шайтан үзе керә алмаган җиргә ... *аракысын җибәрә.*
Аракы аш булмас, бавырга ... *таш булыр.*
Аракы керсә, оят ... *качар.*
Аракы эчкән әҗәле җитми ... *үләр.*
Аракы — явызлыкның ... *башы.*
Аракы әдәмне әдәм итмәс, ... *әрәм итәр.*
Бер йотым аракының бәласе ... *кырык елга барыр.*
Бер кеше дә үзе теләп тиле булмый, ... *эчкән кеше генә була.*
Дөньяда хур буласың килсә, ... *аракы эч.*
Суга таянма, исереккә ... *ышанма.*
Эчү бер кайгыны басса, ун кайгының ... *ишеген ача.*

- Кайсы мәкальләр без укыган хикәягә бигрәк туры килә? (Аракы әдәмне әдәм итмәс, ... *әрәм итәр.* Аракы — гөнаһның ... *анасы.* Шайтан үзе керә алмаган җиргә ... *аракысын җибәрә.* Бер йотым аракының бәласе ... *кырык елга барыр).*

**3. "Исерткеч эчемлек кулланудан ничек котылырга?"**

- Нинди эчемлекләр исерткеч эчемлекләр исеменә керә? Аларны ни өчен чыгаралар?
- Аракы, пиво, шәраблар. Аларны кешеләрнең күңелләрен күтәрү өчен һәм табыш алу өчен чыгаралар.
- Алкогольнең кеше организмына бик зур зыяны бар. Шуңа күрә аңлы кешеләр кибет киштәләрендә сыгылып утырган исерткеч эчемлекләрнең "һөҗумыннан", аракы колы булудан сакланырга тиеш.
- "Исерткеч эчемлек кулланудан ничек котылырга?" дигән темага уз-узеңне тәрбияләү планын язызыз.
- Сезнең җавапларыгызны безнең фикерләр белән чагыштырыйк:

План.

1. Физкультура һәм спорт белән шөгыльләнергә.
2. Ихтыяр көчен тәрбияләргә.
3. Үз-узеңдә алкогольга каршы нәфрәт, котылу теләге булдырырга тиеш.
4. Нәселдә эчкән кешеләрне барларга һәм тиешле нәтиҗә ясарга.
5. Файдалы, яраткан шөгыль (хобби) булдырырга.
6. Аракы белән агуланган кешегә үз теләгең белән дәваланырга барырга кирәк.

**4. Изге Коръән китабыннан.**

Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) янына килгәннәр дә хәмер вә отыш уеннары турында сораганнар. Бу хакта Коръәндә дәлилләр китерелгән:

- ***«Әгәр синнән сорыйлар икән хәмер вә мәэсир (отыш уеннары) турында, әйт: «Аларда зур гөнаһ бар ».*** (Коръән. 2: 95).
- ***«И иман китергән бәндәләр, хәмер вә отыш уеннарыннан, потларга табынулардан, күрәзәчелек вә багучылыктан ерагаегыз».***

**-** Аллаһы Тәгалә исерткечне бөтенләй тыя. Безнең бабалар аракының нәрсә икәнен дә белмәгән. Аллаһы Тәгалә безне шушы бозыклыклардан Үзе сакласа иде. Киләчәктә үз бабаларыбыз тоткан Ислам динендәге булган барлык нигезләрен үтәп яшәргә насыйп әйләсен.

**4. Хәдисләр.**

- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең хәдисләрен укып, алар турында үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

- ***"Әгәр бераү хәмер эчсә, иманы аны ташлап чыгар".***
- ***«Әгәр кеше бер тамчы булса да хәмер эчсә һәм шушы кырык көн эчендә үлсә, ул бу дөньядан кәфер рәвешендә китә».***

- Бу сүзләр турында үз фикерләрегезне әйтегез.

- Аллаһы Тәгалә аракыны хәмер дип атады һәм зарары зур дип белдерде. Җитмәсә, ул хәтерне бетерә, ашказанына зыян китерә, рухыбызны җимерә, ягъни ихтыяр көчен юк итә. Адәм баласы рухи да, физик яктан да аракыдан бары зыян гына ала. Зарары көндәлек тормыш үзе күрсәтеп тора.

**5. Танылган шәхесләргә сүз бирик.**- *Танылган бер шәхесләр болай дигәннәр:*

Ф. Ламенне- француз философ, христиан дин әһеле

- *"Калтыраган кулы белән стаканны тотып эчкән кеше нәрсә эчкәнен беләсезме? Ул үз хатынның, үз балаларының күз яшен, канын, гомерләрен эчә. "*

**6. Эпиграф өстендә эш.**

- Бүгенге дәреснең эпиграфы: "Дөньяда хур буласың килсә, аракы эч" .

(Татар халык мәкаләсе)

- Бу сүзләре ничек аңлыйсыз?

- Аракы эчкән кеше иртәме, соңмы бу дөньяда да ахирәттә дә хур булачак икәнең онытмагыз. Бәхетле буласыгыз килсә- аракы колы булмагыз!

**V. Рефлексия (Йомгаклау).**

**-** Дәреснең темасын искә тешерегез.

- Югарыда сөйләгәннәрдән чыгып, үзең өчен нинди сабак алып була? *(Эчүчелек-афәт, эчүчелек-үлем ул!)*

- Акыллы кешегә аракы эчү кирәкме? Ни өчен? (*Аракы - гөнаһның анасы*).

- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз? (*Бәхетле буласы килгән кеше аракы эчми*).

- ***"Дөньяда хур буласың килсә, аракы эч"***- Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграф итеп тактага яздык. Җөмләне хор белән кабатлыйк һәм үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчанда онытмыйк.

- Димәк, без бүген аракының гаиләгә, кешегә үзенә булган зыяны турында сөйләштек.

**VI. Өйгә эш:**

Өй эшен вариантлап бирәбез:

1. Аракының кеше организмына китергән зыяны турында информация эзләү.
2. "Аракы эчү- бәхетсезлек" дигән темага җавап әзерләү.